**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**28.10.2019 ел**

**КАРАР**

**№4**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске авыл җирлегенең Иске Имән авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, к а р а р б и р д е:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Иске Имән авылы клуб бинасында 2019 елның 14 ноябренә 13.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2020 елда үзара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

- Иске Имән торак пунктының Мулланур Вахитов, Нәҗип Вахитов, Каратал урамы буенча юлларга вак таш җәю (таш ташу);
-Иске Имән торак пунктының җирле әһәмияттәге юлларын кышын кардан чистарту;
- Иске Имән торак пунктында Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

-Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу;
-Иске Имән торак пунктларында урам утларын ремонтлау (лампаларны алыштыру) ;

"ӘЙЕ"                    “ЮК”.

3.Иске Имән авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.
4. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, Иске Имән, Сарысаз Тәкермән авыллары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге башлыгы:                    Р.Ә.Исламова